Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

11 май 2018 ел № 240

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советының
2006 елның 3 февралендәге “Татарстан
Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Советының депутат статусы
нигезләмәсе турында” 37 нче номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 елның 18 апрелендәге “Җирле үзидарәне оештыруны камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” №83-ФЗ Федераль закон, 2018 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” №273-ФЗ Федераль Закон нигезендә, Әлмәт шәһәре прокурорының 2018 елның 27 февралендәге №143 күрсәтмәсен карап,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 3 февралендәге “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының депутат статусы нигезләмәсе турында” 37 нче номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 4 июлендәге №306, 2015 елның 13 мартындагы №455, 2015 елның 10 декабрендәге №40, 2017 елның 27 июлендәге №191 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар кушымтасындагы 2 нче статьяның 3 өлешен “Депутат вәкаләтләре срогы” түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Депутатның вәкаләтләре срогы муниципаль район составына керүче җирлек башлыгы вазифасына керешүдән яисә әлеге җирлек советы депутаты, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты булып сайланганнан соң (алга таба – район Советы) башлана һәм җирлекнең яңа сайланган башлыгы вазифаларына керешкән көннән яки җирлектәге депутатның район Советы составына чираттагы сайлану турындагы карарның үз көченә кергән көненнән тәмамлана.”.

1.2. карар кушымтасын түбәндәге эчтәлекле 19.1 статьясы белән тулыландырырга:

“19.1. статья. Ышанычны югалтуга бәйле рәвештә муниципаль вазифаларны биләүче затларны эштән алу (вазифаларыннан азат итү)

1.Татарстан Республикасы законнарында, федераль законнарда, муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә муниципаль вазифа биләүче зат ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән алына (вазифасыннан азат ителә):

1) яклар тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрмәгәндә;
2) зат үзенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре. мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырылмаган яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргәндә;
3) затның коммерция оешма белән идарә итү органы эшчәнлегендә түләүле нигездә катнашуы, федераль законнар билгеләгәннән тыш;
4) эшмәкәрлек эшчәнлеген зат тарафыннан гамәлгә ашыру;
5) әгәр затның Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке, оешманың һәм Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган структур бүлекчәләренең попечительләр яки күзәтү советлары белән идарә итү органнары составына керү.

2. Үзенә буйсынган затның шәхси кызыксынуы барлыкка килүе турында мәгълүм булган муниципаль вазифа биләп торучы зат ышанычны югалтуда бәйле рәвештә эштән азат ителергә тиеш.

3.Муниципаль вазифа биләгән затка ышанычны югалтуга бәйле рәвештә коррупцион хокук бозган өчен  дисциплинар шелтә белдерү (эштән азат итү) җирле үзидарә органы тарафыннан  2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” 273 номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгәннәр реестрына кертелә.

2. Район башкарма комитеты хокук идарәсенә (Шәйхулова Ф.Х.) әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырып чыгарырга, “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә, әлеге карарның 1.2. пункты 2018 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен бирә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының закон, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (И.Р.Баһманов) йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин